## 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Күләй авылы җирлеге Күләй тимер юл станциясе бистәсе гражданнарның үзара салымын кертү турында

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

15 ноябрь 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Күләй авыл җирлегенең Күләй тимер юл станциясе бистәсе гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Урман- Күләй авыл җирлегенең Күләй тимер юл станциясе бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан,1 нче группа инвалидлардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (скважинаны төзекләндерү һәм тоташтыру, скважинаны тоташтыру һәм бәйләү өчен кирәкле материаллар сатып алу) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, торак пункт чикләрендәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу/юлларга асфальт салу, асфальт юллардагы чокырларны ремонтлау, юлларга вак таш салу)?».

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Күләй тимер юл станциясе бистәсе, Железнодорожная урамы,38б йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урман- Күләй авыл җирлеге башлыгы Л.Н. Фәләхиев